ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2019 1889

2020 елның 1 яртыеллыгына социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле сыйфатта булмаган һәм (яки) билгеләнгән озынлыктан артып киткән тәнәфесләр белән», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре халкы өчен 2020 елның 1 яртыеллыгына социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак

урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен расларга (1 нче кушымта).

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре халкы өчен 2019 елның 2 яртыеллыгына социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2019 елның 21 июнендәге 1004 номерлы карарын 2020 елның 1 гыйнвареннән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга һәм үз гамәлен 2020 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Ф. Нургаяновка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 25.12.
1889 нче(ы) номерлы
карарына 1 нче кушымта

Социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту буенча түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы торак урыннар хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга күрсәтелгән хезмәт төрләре буенча 2020 елның 1 гыйнварыннан түләү күләме

| № т/б | **Хезмәтнең исеме** | **Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум.** | **Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда)** |
|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2020 ел. 30.06.2020 ел. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 3,86 |
| **2** | Уртак милек составына керүче гомуми файдалану урыннарын, шулай ук җир участогын санитар яктан карап тоту, шул исәптән: | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | **23,42** |
| | -йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру; | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 3,44 |
| | - йорт яны территориясен җыештыру | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 4,62 |
| | - чүп чыгару торбасын карап тоту; | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 3,25 |
| | - дератизация | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 0,18 |

| №<br>т/б | **Хезмәтнең исеме** | **Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум.** | **Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда)** |
|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2020 ел.<br>30.06.2020 ел. |
| | - торак биналарның конструктив элементларын агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 2,62 |
| | - йорт эчен су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 2,13 |
| | - үзәк җылытуның йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау; | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 2,13 |
| | - йорт эчендәге электр челтәрләренә һәм җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау; | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 1,02 |
| | -йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 0,27 |
| | - йорт эчендәге вентиляцион каналларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау; | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 0,13 |
| | -1 каттан лифтларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 3,63 |
| 3 | Сыек көнкүреш калдыкларын суыртып алу һәм чыгару | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 152,10 |
| 4 | Газ җиһазларына хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 21,53 |
| 5 | Наем өчен түләү (яллаучылар өчен) | торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м. | 6,11 |